ЯКШӘМБЕ
21 АПРЕЛЬ
1940 ел
№ 92 (5892)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация һәм совет төзелеше бүлекләре 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

НАВИГАЦИЯНЕ БОЛЬШЕВИСТИК ОЕШКАНЛЫК БЕЛӘН ҮТКӘРИК

Орденлы Татарстан республикасы аша үтә торган киң һәм күп сулы Волга һәм Кама елгалары боздан тулысынча чистарындылар. Хәзер монда кызу эш — навигация башланды. Пристаньнәребез беренче пароходларны, баржаларны һәм пассажирларны кабул иттеләр. Елгаларда җанлы хәрәкәт туды.

Партиябез һәм хөкүмәтебезнең турыдан-туры иптәш Сталинның көндәлек кайгыртучанлыгы белән чолганып алынган елга флоты работниклары 1940 нчы ел навигациясен узган елларга караганда күп кенә яхшы күрсәткечләр белән каршыладылар. Судноларга, причал һәм пристаньнәргә, склад хуҗалыкларына ремонт эше нигездә яхшы билгесенә тәгәлләнде. Судно һәм пристань коллективлары барсы да бердәм фикер белән, алда торган мактаулы һәм җаваплы бурычларны большевикларча башкару хисе белән, йөк ташу һәм пассажирлар йөртү буенча дәүләт планын тәгәл үтәү хисе белән сугарылганнар. Бердәм теләк—су юлы транспортының артта калучылыгын бетерү турында партиябезнең тарихи XVIII нче съезды куйган күрсәтмәләрен тайпылышсыз үтәү тирәсенә барлык көчне, барлык игтибарны туплауга кайтып кала.

Алда торган бу бурычларны тулы һәм намусбелән үтәү өчен елга флоты работникларына барлык шартлар һәм барлык мөмкинлекләр тудырылган. Моны без Казан пристане мисалендә дә ачык күрә алабыз. Монда быел йөк төяү-бушату эшләре тулысы белән механикалаштырылды. Йөк төяү лабазлары мәйданы киңәйтелде, эш өчен уңай шартлар тудырылды. Бу исә эшне тизләтүгә ярдәм итә, хезмәтне җиңеләйтә. Хезмәтне һәм эш урнын оештыру өлкәсендә республикабызның башка пристаньнәрендә дә күп кенә яңа һәм практик чаралар үткәрелде.

Пассажирларга культуралы хезмәт күрсәтү өлкәсендә дә зур эшләр башкарылды. Ял итү бүлмәләре, ашханәләр, рестораннар, балалы аналар өчен махсус бүлмәләр, барсы-барсы да тулы зерлеккә һәм тәртипкә китерелделәр. Эре пристаньнәребез радиолаштырылды. Ял итү бүлмәләре газета-журналлар һәм күңел ачу уеннары белән тәэмин ителделәр. Казан пристанендә тиздән кино-театр ачыла.

Хәзер бурыч, беренче башлангычны тагын да яхшырак эшләү белән ныгытудан, дәүләт заданиеләрен тулы үтәү тирәсенә масса игтибарын туплаудан, клиентура белән үрнәк эшләүне оештырудан гыйбарәт. Моның өчен пристань. причал һәм судно коллективлары арасында политик-тәрбия эшләрен, стахановчылык-блидманчылык хәрәкәтен большевикларча оештырырга, һәрбер работникның, һәрбер участокның үзара ярышын әшләвенә, хезмәт дисциплинасын тиешле югарылыкта булуына, узган елгы җитешсезлекләргә һич нинди да юл куелмауга ирешергә кирәк. Алдынгы коллективлар үз эшләрен әле шул таләпләрдән чыгып оештыралар.

Чистай һәм Кама Тамагы пристаньнәрендә партия, профсоюз оешмалары үз сафларыннан ин яхшы кешеләрне, партияле һәм партиясез большевикларны конкрет эш участокларына беркетәләр. Агитколлективлар эшен сыннан эшкә башладылар. Монда социалистик ярыш договорларын төзү эше тәгәлләнде. Бу договорларда һәрбер работник үз өстенә конкрет йөкләмәләр ала.

Партия, профсоюз һәм хуҗалык оешмалары үз игтибарларын беренче көнгәннән үк, навигациядән соң социалистик ярышны һәм стахановчылык хәрәкәтен чын-чынлап массовый төс бирүгә юнәлдерергә, социалистик договорларның үтәлешен әледән-әле тикшереп торуга һәм аларның һич шиксез үтәлүләренә ирешү тирәсенә тупларга тиешләр. 1940 нчы ел навигациясе елга флоты работникларыннан беренче көннәреннән үк тегел эшләүне, һәрбер договорның үтәлешен тикшерүне таләп итә.

Кадрларны дөрес урнаштыру, аларга тиешле эш һәм тормыш шартларын тудыру турында пристань житәкчеләре көндәлек кайгыртучанлык күрсәтергә тиешләр. Үз эшләре техникасын отличнога үзләштергән стахановчылар, ударниклар елга флотында аз түгел. Алар навигациягә яхшы хәзерләнүне тәэмин итүдә зур роль уйныйлар. Навигация планын үтәү өчен көрәштә дә алар һич шиксез, алдынгы сафта булачаклар. Бу алдынгыларның бай тәҗрибәләрен артта калучыларга күчерү эшен үрнәкле итеп оештырырга кирәк.

Навигация башланды. Алда зур бурычлар тора. Стахановча-блидманча эшләүнең большевистик үрнәкләрен күрсәтеп, иптәшләр 1940 нчы ел навигациясе планын вактыннан элек үтәп чыгыйк. Социалистик ярыш байрагын моңа кадәр булмаган дәрәҗәдә югары күтәрик!

Партиянең Казан шәһәр активы җыелышы тәмам булды

Партиянең шәһәр активы җыелышының кичәге утырышында ВКП(б) Үзәк Комитетының март пленумы йомгаклары турындагы доклад буенча фикер алышулар дәвам итте. Трибунада ВКП(б) ның Юдино райкомы секретаре иптәш Захаров.

— ВКП(б) Үзәк Комитетының март пленумы карарлары, ди үзенең чыгышында иптәш Захаров,— безнең колхоз төзелеше тарихына колхоз строен тагын да ныгыту буенча иң әһәмиятле чаралар сыйфатында керер. Бу карарлар безнең партиябез, хөкүмәтебез тарафыннан һәм бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин тарафыннан колхозларга һәм колхозчы крестьяннәргә никадәр зур игтибар бирелгәнлекне һәм алар турында никадәр кайгыртучанлык күрсәтелгәнлекне бөтен ачыклыгы белән тагын бер кат раслыйлар.

ТАССР Совнаркомы председателе иптәш Гафиятуллин үзенең речен хәзерләүләр оешмаларының эшендә булган гаять зур кимчелекләрне бетерү мәсьәләсенә багышлый. Ул үзенең чыгышында соңгы вакытка кадәр республикабызда хәзерләүләр буенча яшәп килгән оешмаларның күп санда булып та эффектлы эш алып бармауларын, дәүләтнең бик зур сумаларын рациональ төстә тотмауларын чагылдырган ачык мисальләр китерә. Хәзерләүләр оешмаларын ныгыту, аларның эшен яхшырту буенча Казан шәһәр партия оешмасы алдына конкрет бурычлар куя.

ВКП(б) ның Биектау район комитеты секретаре иптәш Кузнецов колхозчылар массасы тарафыннан пленум карарларының яхшы итеп табылганлыгын әйтеп, районда кошчылык фермалары оештыру буенча зур эшләр башлану турында сөйли.

Татарстан АССР Җир Эшләре Халык Комиссары Черзор, Хәзерләүләр Халык Комиссариатының Татарстандагы Уполномоченные Никишкин иптәшләр үзләренең чыгышларында ВКП(б) Үзәк Комитетының март пленумы карарлары нигезендә җир органнары, хәзерләүләр оешмалары алдында торган конкрет бурычларга тукталдылар.

ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Матвеев ВКП(б) Үзәк Комитеты пленумы карарларының авыл хуҗалыгын, колхоз строен тагын да ныгыту буенча сугышчан программа булганлыгы һәм бу бөек бурычларны үтәү буенча партиянең Татарстан оешмасы алдында нинди конкрет бурычлар торганлыгы, аерым алганда язгы чәчүне уңышлы үткәрү, социалистик терлекчелекне тагын да үстерү өлкәсендәге бурычлар турында сөйләде.

Иптәш Матвеев чыгышыннан соң фикер алышулар туктатылды. Барлыгы 15 кеше сөйләде. Аннары ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Алемасов сорауларга җаваплар бирде. Һәм Татарстан большевикларын ВКП(б) Үзәк Комитеты пленумы карарларын үтәү буенча большевикларча көрәшергә чакырды.

Шуннан соң актив җыелышы ВКП(б) Үзәк Комитеты пленумы карарларын бердәм рәвештә яхшы дип тапты һәм карар кабул итте.

Шуның белән партиянең шәһәр активы үзенең эшен тәмам итте.

ТУФРАК ХӘЗЕРЛӘҮ БЕЛӘН ЧӘЧҮ АРАСЫНДА ӨЗЕКЛЕККӘ ЮЛ КУЙМАСКА

Тиз һәм яхшы сыйфатлы итеп чәчәргә

Республикабызның колхозлары, совхозлары авыл хуҗалыгы елының иң җаваплы чорына керделәр. Бер-ике көннән барлык районнарда да чәчү массовый төстә башланачак. Партия, совет оешмалары, җир органнары алдында торган иң зур бурычларның берсе: язгы чәчүнең беренче көннәренең барлык сабакларын искә алып, алдынгыларның тәҗрибәләрен киң рәвештә популярлаштыру, ясалган ялгышларны кичекмәстән төзәтү, аларның кабатлануына юл куймаудан гыйбарәт.

Язгы чәчүгә үрнәк рәвештә хәзерләнгән, һәрбер колхозчыга аның алдында торган бурычларны яхшы аңлаткан, социалистик ярышны киң рәвештә җәелдергән алдынгы колхозларда язгы кыр эшләре зур оешканлык белән, бердәм рәвештә башланды. Бу колхозларда чәчүнең беренче көннәрендә үк колхозчылар, тракторчылар хезмәт җитештерүчәнлегенең гүзәл үрнәкләрен күрсәттеләр. Мисальгә Әлмәт районының „Ирек“ колхозын, Баулы районының „Свободный труд“, „Новая деревня“ колхозларын алырга була.

„Ирек“ колхозында чәчү башлануга кадәр трактор бригадасы белән кырчылык бригадалары арасында эшне дөрес итеп оештыру буенча план төзеделәр һәм чәчү башлану белән бу план үзенең көчен, кыйммәтен тулысы белән аклаганлыгын күрсәтә. Чәчү эшләре вактында һәм оешкан төстә башлана, эш процесслары арасында бернинди өзеклеккә юл куелмый. Нәтиҗәдә эшнең темпы һәм сыйфаты яхшы. Чәчүнең беренче көненнән үк тракторчылар югары күрсәткечләр бирәләр. Тракторчы иптәш Шириазанов беренче көнне 61 гектар урнына 72 гектар, ә икенче көнне 78 гектар чәчә.

„Свободный труд“ колхозыннан Заитов һәм Можгин, „Новая деревня“ колхозыннан Сабанаев һәм Афанасьев иптәшләр нормаларын һәр көнне 150—190 процент итеп үтиләр. Мондый мисальләрне күп китерергә мөмкин.

Кыр эшләрен вактында башлауны „әле җир өлгермәгән“, „туфрак юеш“ дигән сылтау астында сузып килүче колхозлар да бар әле. Мондыйлар рәтенә Кызыл Армия районының „Восход“, „Алга № 2“, „Красное Поляна“ колхозларын кертергә кирәк. Бу колхозларның кырларында күп кенә участкылар өлгергән булуга да карамастан, „юешлек“ сылтавы астында бу көнгә кадәр язгы чәчү эшләренә керешмәгәннәр. Шунсы гаҗәп, бу хәл район җир бүлеге җитәкчеләренә билгеле булса да, алар кабинетта утырудa дәвам итәләр.

Язгы чәчүнең уңышлы үткәрелүе машина-трактор паркыннан һәм җанлы тарту көчләреннән дөрес һәм тулысынча файдалануга бәйләнгән. Шунлыктан, МТС җитәкчеләренең төп игтибары участкыларга барлык тракторларны тулысынча яхшы хәлдә җибәрүгә, кырда аларның токтарсыз эшләүләрен тәэмин итә торган чараларны күрүгә тупланырга тиеш. Ләкин кайбер урыннарда бу эшкә бөтенләй игтибарсыз һәм җавапсыз карау фактлары бар. Мәсәлән, Шөгер районының „Үзәк“ МТС ы җитәкчеләре тракторларны участкыларга кирәгенчә тикшермичә җибәргәннәр.

Бу МТС җитәкчеләре үзләренең мондый җавапсызлыклары белән язгы чәчү эшләрен сузганлыкларын аңларга һәм моннан кирәкле нәтиҗә ясарга тиешләр.

Кайбер колхозларда чәчү эшләрендә атлардан файдалану эше начар оештырылган. Бу фактларны Заинский районында очратырга була. Язгы чәчү вактында барлык атлар һич шиксез тулысынча файдаланылырга тиеш.

Кыр эшләренең сыйфаты өчен көрәш—ул, югары иген уңышы өчен көрәшнең иң әһәмиятле шартларыннан берсе. Шуңа күрә, сөрүнең, тырмалауның, чәчүнең агротехника кагыйдәләренә туры китерелеп үткәрелүенә, бер эш белән икенче эш арасында бернинди өзеклек тудырмауга игтибар итү—партиянең һәрбер оешмасының, колхоз, совхоз һәм МТС җитәкчесенең төп бурычы.

Язгы чәчүне иң кыска срокта һәм яхшы сыйфатлы итеп үткәрү өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар.

Алдынгылар тәҗрибәсен популярлаштыру, социалистик ярышны тагын да югары баскычка күтәрү нигезендә язгы чәчүне уңышлы үтәп, Беренче Май бәйрәмен лаеклы рәвештә каршылыйк.

Лаеш районы Рождественский МТС трактор отряды Сталин исмендәге колхоз кырларына эшкә чыгалар.

С. Чиколкин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ИРТӘ КУЛЬТУРАЛАРНЫ ЧӘЧҮ ТӨГӘЛЛӘНДЕ

ЮТАЗЫ, 20 апрель. (Телефон буенча). Бүген 20 нче апрельдә „Кыска елга“, „Свободный труд“ һәм „Яссы тугай“ колхозлары иртә культуралар чәчүне төгәлләделәр.

„Кыска елга“ колхозы чәчүчеләреннән Хафизов, Хәкимев һәм Исмагыйлов иптәшләр норманы системалы рәвештә 120—130 процент, „Свободный труд“ колхозы чәчүчеләреннән Коробков һәм Киселев иптәшләр 130—160 процент үтәделәр. Эшнең сыйфаты яхшы. Бу колхозларның өчесендә дә иртә культуралар чәчү бары 5—6 көн барды.

Кузеев.

Чәчүне соңга калдыралар

КАРГАЛЫ, 20 апрель. (Телефон буенча). Кызыл Армия районының күпчелек колхозларында кыр эшләре массовый төстә бара. „Марс“, „Алга“, Киров һәм Нәриман исмендәге колхозлар 50—60 гектар иртә культуралар чәчтеләр инде. Бу колхозларда һәрбер өлгергән участкыларны эшкәртү, шунда ук чәчү чаралары күрелә.

Ләкин районның кайбер колхозлары нәрсәдер көтәләр, туфрак өлгерүгә карамастан, һаман да кыр эшләренә керешмиләр. Шулай итеп туфрактагы дымның әрәм булуына юл куялар. „Восход“ (председателе иптәш Захаров), „Алга № 2“ (председателе иптәш Хөснуллин), „Путь Ленина“ (председателе иптәш Федоров) һәм „Красная Поляна“ (председателе иптәш Боткин) колхозлары әле һаман да кыр эшләренә керешкәннәре юк.

Туфракны эшкәртү белән чәчү арасында зур өзеклек тудырыла. Хәзер колхозларда 923 гектар яз сөрелгән, 1.860 гектар тырмаланган һәм 801 гектар культивацияләнгән җир бар. Шуның әле бары 286 гектары гына чәчелгән.

Ужым тырмалау буенча да шундый ук хәл. Районда бүгенге көнгә әле бары 35 гектар ужым тырмаланган.

Кыр эшләренең сыйфатына әһәмият бирелми. Каргалы МТС ының „Динамо“ һәм „Ирек“ колхозларында эшләүче тракторлары сай һәм чи калдырып, „Беренче Май“ колхозында фигуралап сөрәләр. Бу колхозларда сөрүнең тирәнлеге 12—13 сантиметрдан артмый. „Динамо“ колхозында 3 гектар сөрелгән җир брак дип табылды.

Район җир бүлеге мөдире Гатауллин, агроном Хәйреттинев, Лазарев һәм Измайлов иптәшләр урынга барып бу җитешсезлекләрне бетерүдә кискен чаралар күрү урнына, кабинетларында тыныч кына утыра бирәләр. Иптәш Гатауллин кыр эшләре башланганнан бирле әле бары бер колхозда булган.

Мотыйгуллин.

Кыр эшләрен чиратка куюның күңелсез нәтиҗәсе

ШӨГЕР, 20 нче апрель. (Махсус хәбәрчебездән телефон буенча). Өлгергән Участкыларны сайлап сөрү һәм тырмалау эшләре башлануга атнадан артык вакыт үтте. Димәк, участкыларның өлгерүләренә карап, агрономия күрсәтмәләре нигезендә ужымнарны тырмалау, тукландыру эшләре дә шушы вакытта башланырга тиеш иде. Ләкин районда бу турыда онытгылар. Ужымнарны тырмалау эшенә 20 нче апрельдә райондагы 48 колхозның бары 5 е генә башлаган, ә тукландыру эшенең барышы турында район җир бүлегендә бөтенләй белмиләр. Бу эшкә 3 колхоз („Байрак“, „Үрнәк Күмәк“ һәм Куйбышев исмендәге колхозлар) гына керешкән әле. Бу хәл, барыннан да элек, эшне чиратка куеп эшләүдән килеп чыга. Кайбер колхозларның председательләре ужымнарны тырмалау һәм тукландыру эшенә ачыктан-ачык бәя бирмиләр. Мондыйлар рәтенә „Үзәк“, „Ярыш“, „Пролетарий“, „Магнит“ колхозларын кертергә мөмкин.

Язгы кыр эшләрен үткәрү буенча ВКП(б) райкомы һәм район җир бүлеге тарафыннан колхозларга ярдәмгә җибәрелгән вәкилләр бу фактны читләтеп үтәләр һәм шуның белән агрономия күрсәтмәләрен бозуга юл куялар. Сүз уңаенда әйтергә кирәк, Татнаркомзем тарафыннан җибәрелгән агрономия күрсәтмәләре моннан бер атна элек килүгә карамастан, район җир бүлеге аны колхозларга җибәрмәгән.

М. Хәмидуллин.

ТРАКТОРЛАР ТИК ТОРА

Красный Бор районы колхозларында кыр эшләренең беренче көннәре тракторларга һәм сабаннарга ремонтның сыйфаты начар булганлыкны күрсәтте. Алексей Гоголев һәм Новокрещенов иптәшләрнең бригадаларында сабаннарның төрәннәре юк. 9 нчы бригадада СТЗ-НАТИ тракторының радиаторы ага, „Прикамец“ колхозындагы 2 тракторның подшипниклары эрегән, шунлыктан алар тәүлек ярым эшли алмый торганнар. Күчмә мастерской оештырылмаган. Бер генә тракторда да фаралар юк. Шунлыктан тракторлар төнлә эшли алмыйлар. (ТатТАСС).

* * *

Октябрь МТС ы дирекциясе (директоры иптәш Беляев) 5 нче апрельдә үк инде Татнаркомземга тракторларга ремонт ясауның тулысынча төгәлләнүе турында мәглүматлар биргән иде. Соңыннан билгеле булганча, ремонт әле дә төгәлләнмәгән. Иптәш Сиражеттинов бригадасындагы ике СТЗ тракторында зур гына кимчелекләр бар. Бу тракторлар 17 нче апрельдә дә эшкә керешә алмадылар. „За урожай“ колхозында радиаторлары төзек булмаганлыктан, тракторлар эшли алмыйлар.

Бердәм план белән

ӘЛМӘТ, 20 апрель. (Телефон буенча). 10 нчы номерлы трактор отрядының бригадиры иптәш Гарипов „Ирек“ колхозына килү белән бригадирлар катнашы белән правление утырышын җыюны сорады. Бу утырышта иптәш Гарипов трактор бригадасы белән кырчылык бригадалары арасында эшне уртак план буенча алып баруның әһәмияте турында сөйләде. Шушы утырышта трактор бригадасының һәм ул хезмәт күрсәтәчәк бригадаларның язгы кыр эшләре планнары тикшерелде. Трактор бригадасына прицепшиклар итеп колхозның иң алдынгы кешеләре беркетелде.

Икенче көнне иптәш Гарипов трактор бригадасына хезмәт күрсәтәчәк барлык колхозчыларны җыйнады. Ул аларга трактор бригадасы алдында торган бурычларны аңлатты. Тракторларга, тагылма машиналарга, тракторларны көйләү һәм заправка инвентарьларына яңадан бер тапкыр тикшерү үткәрелде.

Колхоз кыр эшенә вактында керешге. Эш кырчылык һәм трактор бригадасының алдан төзелгән бердәм планы нигезендә алып барыла. Үзара контроль яхшы. Кырчылык бригадалары трактор бригадасының эшенә якыннан торып булышалар. Алар трактор бригадасы тарафыннан башкарылган эшне системалы рәвештә тикшереп акт белән кабул итеп баралар. Ә трактор бригадасы үз чиратында алардан орлыкларның югары сыйфатлы һәм яровойлаштырылган булуын таләп итә.

Әнә шулай эшләү беренче көннәрдә үк, яхшы нәтиҗәләр бирде. Туфрак хәзерләү белән чәчү арасында өзеклеккә һич тә юл куелмый. Чөнки планда бу нәрсә конкрет рәвештә күрсәтелгән.

Тракторчылардан иптәш Шириазанов 17 нче апрельдә 61 гектар урнына 72 гектар, 18 нче апрельдә 78 гектар чәчте. 15 нче апрельдә тракторчы иптәш Вәлиев норманы 135 процент итеп үтәде. Ул шул көнге эше өчен 58 сум 75 тиен акчалата һәм шуның өстенә 70 килограмм ашлык алырга тиеш.

Трактор бригадасы үз эшен яхшы сыйфатлы итеп вактыннан алда үтәве өчен уңышлы көрәш алып бару белән бергә, кырчылык бригадаларының эшләре белән дә нык кызыксына. Көнлек эш нәтиҗәләре бригаданың һәр көн үткәрелә торган производство киңәшмәләрендә тикшерелә һәм кимчелекләр эш барышында ук бетерелә барыла.

З. Салахеттинов.

Кок сагыз чәчә башладылар

Татарстан районнарында каучуклы кок сагыз чәчү бушланды. Беренче булып Шөгер районының „Кызыл Яр“ колхозы 3 гектар мәйданга кок сагыз чәчте. Татарстанның Кама арты районнарында быел барлыгы 205 гектар кок сагыз чәчеләчәк. (ТатТАСС).

ТАСС НЫҢ ЮККА ЧЫГАРУЫ

1. Англиянең „Ньюс кроникл“ газетасы һәм Франциянең Гавас агентлыгы гүяки СССР белән Румыния арасында Франциянең Румыниядәге илчесе катнашы белән сөйләшүләр алып барылу турында, Совет һәм Румыния гаскәрләрен чиктән 10 километрга алып китү буенча килешүгә ирешелү турында хәбәрләр тараталар. Бу хәбәрнең баштан алып ахрына кадәр уйдырма икәнлеген белдерергә ТАСС ның вәкаләте бар.

2. Чит ил матбугаты Совет хөкүмәтенең Москвага киләчәк Көньяк Славия делегациясе белән булачак политик сөйләшүләре турында һәм бу сөйләшүләрнең максаты, гүяки, Көньяк Славиянең күршеләре белән мөнасәбәтләрен ныгытудан гыйбарәт булачак икәнлеге турында хәбәрләр тарата. Бу хәбәрнең тулысы белән ялган икәнлеген белдерергә ТАСС ның вәкаләте бар. Чынлыкта Москвага ике ил арасында сәүдә мөнасәбәтләре урнаштыру мәсьәләләре буенча СССР ның тиешле хуҗалык органнары белән сөйләшү өчен Көньяк Славиядән хуҗалык делегациясе килә.

3. Совет—Япония сәүдәсе мәсьәләләре буенча Тышкы Сәүдә Халык Комиссары иптәш Микоянның Япония илчесе Того әфәндене күптән түгел генә кабул итүе уңае белән Япония матбугаты СССР ның көньяк-көнчыгышта һәм гомумән Европада үзенең кулларын чишеп җибәрү өчен нинди генә бәягә булса да Япония белән килешү эзләве турында хәбәрләр тарата. Бу хәбәрләрнең һич тә дөрес түгеллеген һәм көлке икәнлеген белдерергә ТАСС ның вәкаләте бар, чөнки Ерак Көнчыгышта мәглүм обстановка булганлыктан, СССР белән килешүгә барыннан да элек нак японнар мохтаҗ икәнлекне, ләкин киресенчә түгеллекне японнар аңламый кала алмыйлар.

Күргәзмәгә хәзерлекне көчәйтергә

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә быел катнашуга кандидатлар сайлап алу һәм документларны рәсмиләштерү эше төгәлләнде.

Татарстан АССР дан барлыгы 6.922 заявление (колхозлардан—369, совхозлардан—7, МТС лардан—9, колхозларның товарлыклы фермаларыннан—206, фәнни учреждениеләрдән—8, авыл хуҗалыгы алдынгыларыннан һәм белгечләрдән—6.323 заявление) керде.

Актаныш, Сарман, Тәтеш, Азнакай һәм Мөслим районнары күргәзмәдә катнашуга кандидатлар сайлап алу буенча яхшы эшләделәр. Актаныш районыннан 662 заявление, Сарманнан 447, Тәтештән 336, Азнакайдан 280 һәм Мөслим районыннан 226 заявление керде.

Ләкин күргәзмәгә катнашуга хәзерлек эше моның белән генә төгәлләнде дип һич тә әйтеп булмый. Хәзер алда тагын да әһәмиятлерәк бурыч—күргәзмәгә җибәрү өчен экспонатлар хәзерләү тора.

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе Баш Комитетының планы буенча күргәзмәгә Татарстан АССР дан экспонатлар җибәрү 15 нче мартта башланды. Ләкин бу эш бик акрын бара. Экспонатлар җибәрүгә Буа районының „Первое Мая“, „Чулпан“ һәм „Искра“ колхозлары гына, Минзәлә районының „Яңа Юл“, „Чәчкәле“, „Ядро“, Шөгер районының „Яш Көч“ колхозлары гына керештеләр. Промышленность экспонатлары җибәрүгә дә тик Вахитов исмендәге завод белән сага заводында гына хәзерләнәләр.

Терлекчелек экспонатларын хәзерләү бигрәк тә начар тора. Күргәзмәгә җибәреләргә тиешле терлекләр турында хәзергә кадәр тиешле рәсми документлар һаман да килгәне юк.

Күргәзмәгә хәзерлектә бу төп кимчелекләрне кичекмәстән бетерергә кирәк һәм күргәзмәгә хәзерлек билгеләнгән срокларда төгәлләнергә тиеш.

З. Баһаветтинов.

РЕСПУБЛИКАБЫЗ ЕЛГАЛАРЫНДА НАВИГАЦИЯ БАШЛАНДЫ

КАМА ТАМАГЫ ПРИСТАНЕНДӘ

Кама Тамагы пристане быелгы навигациягә узган елларга караганда яхшырак хәзерлек белән каршылады. Затонда ремонт эшләре нигездә тәмамланды. Ремонтның сыйфаты да начар түгел. Махсус комиссия тарафыннан яхшы һәм отлично билгесенә кабул ителде. Ремонтчылардан байтак кына иптәшләр пароходчылыкның почет тактасына кертелделәр.

Вокзал матур итеп бизәлде, ремонтланды. Билет кассалары, пассажирлар залы, парикмахерская, балалы аналар бүлмәсе, ресторан пассажирларны каршылауга лаеклы хәзерләнделәр. Монда культуралы хезмәт күрсәтү өчен барлык шартлар тудырылган. Вокзал начальнигы Сиротина һәм профорг Әхмеров иптәшләр вокзал работниклары арасында политик-тәрбия эшләрен җәелдерделәр. Социалистик ярыш договорлары төзү эше төгәлләнде.

Пристаньдә сәүдә эшләрен оештыру буенча да күп кенә чаралар үткәрелде. Пассажирларны һәм йөзүче составны кирәкле товарлар белән үз вактында һәм кирәгенчә тәэмин итү өлкәсендә сәүдә оешмаларына зур бурычлар йөкләнә. Монда йөзеп йөрүче 3 лавка, ике зур магазин, 5 ларек, 3 пекарня, ресторан һәм ашханәләр тулы хәзерлеккә китерелделәр. Алар тиешле кадрлар һәм товарлар белән дә тәэмин ителделәр. Бүгенге көндә 300 мең сумнан артык товар хәзерләнгән. Күп кенә товарлар беренче пароходлар белән китереләчәк. Кама Тамагының үзендә 14 тонна ярма, 200 тонна он, 160 тонна бәрәңге һәм башка продуктлар хәзерләнде. Тик менә пристань җитәкчеләре сәүдә работникларына тиешле булышлыкны күрсәтеп житкермиләр әле.

Пристань коллективы үз алдында торган бурычларны үтәүгә хәзер. Коллектив бердәм фикер белән, дәүләт заданиеләрен үз вактында үтәү хисе белән сугарылган. Ул Беренче май алды ярышына зур күтәренкелек белән кушылды һәм навигация планын 7 нче ноябрьгә үтәү, хезмәт җитештерүчәнлеген 150 процентка җиткерү, әйберләрнең үзенә төшкән бәясен планга карата 15 процентка киметү, простой торуларны тулысы белән бетерүгә ирешү йөкләмәсен алды. Шундый конкрет йөкләмәләр буенча 9 нчы январь исемендәге завод коллективы белән ярышка чыкты.

К. Гайнанов.

КВАРТАЛ ПЛАНЫ 116 ПРОЦЕНТ ИТЕП ҮТӘЛДЕ

Кукмара районы, Ядгәр авылындагы „Кызыл бүрекче" промартеле 1940 нчы елның беренче квартал планын 25 нче мартка 116 процент итеп үтәп, 2.100 эш көненә экономия ясады.

Артельдә хезмәт җитештерүчәнлегенең югары күрсәткечләрен бирүче алдынгы стахановчылар күп кенә. Ихсанов, Хәкимова, Таҗиева, Нуриев, Зияттинова, Галиева һәм Хәсәнев иптәшләр көнлек норманы системалы рәвештә 150—220 процент итеп үтиләр.

Г. Идрисев.

Республикабыз елгаларында навигация башланды. Рәсемдә: 19 нчы апрельдә беренче булып Чистайдан Казанга 340 тонна йөк белән килгән „Марксистка" пароходы.

И. Галиев фотосы.

Беренче пароходны каршылаганда

19 нчы апрельдә Казан пристаненә беренче пароход—Кама пароходчылыгының „Марксистка" пароходы килде. 1940 нчы елның навигациясе ачылды.

Беренче пароходны каршылау өчен пристань җитәкчеләре генә түгел, күп кенә хезмәт ияләре дә килгәннәр иде. Пароход килеп җитәргә 5 минут вакыт калу белән, пароходтагы йөкләрне бушату өчен грузчиклар бригадалары хәзерлек эшен башладылар. Ташу карарга килгән йөзләрчә кешеләрнең күзләре дулкын ярып килгән матур пароходка төбәлде.

Әле дебаркадерлар куелмаган. Пароход яр буена туктарга тиеш. Бу шартларда пароходны уңышлы туктату капитан өстендәге җаваплы һәм катлаулы эш.

— Капитан Кузнецов сынатмас,—ди диспетчер иптәш Юзеев.

Дөрес тә капитан Кузнецов сынатмады, пароход яр буена салмак кына килеп туктады.

Пароход командасы да, пароходны кабул итүче ярдагы команда да үз эшләрен җитез һәм төгәл башкардылар, ашыгу, каушау һәм югалып калу кебек күренешләр бөтенләй булмады.

Пароход туктаганнан соң 10 минут та вакыт үтмәде, пароход белән ярны тоташтыручы күпер салынып бетте. Пароходта килгән 200 гә якын пассажир чыгып бетү белән, мичкәләр тәгәрәтеп, капчыклар күтәреп чыгучы грузчиклар күренде.

Беренче пароходны каршылау оешкан рәвештә үтте.

Капитан иптәш Кузнецов беренче рейс турында түбәндәгеләрне белдерде:

— „Марксистка" Чистай затонында ремонтланды. Комиссия ремонтның сыйфатын отлично дип тапты. Безнең беренче рейсыбыз бу бәянең дөрес бирелгән булуын күрсәтте, пароход үзен бик яхшы тота.

„Кама Тамагыннан алып Түбән Осланга кадәр булган ара иң авыр участкы булды. Безнең пароход монда бозлар арасында хәрәкәт итте, ләкин аның бер җире дә зарарланмады. Без Казанга 200 гә якын пассажир һәм 324 тонна йөк (ярма, он) алып килдек. Пароход Казанда бер тәүлек торачак һәм аннан Тихая Гора (Бондюг) пристаненә китәчәк. Казаннан районнарга киң куллану товарлары алып китәбез".

„Марксистка" пароходында Казанга килгән пассажирлар:

— Пароходта бик яхшы килдек, уңай да, җылы да булды, тик пароходта буфет ачуны гына булдыра алмаганнар, диләр. Торгречтранс җитәкчеләре бу кимчелекне якын арада төзәтергә тиешләр.

Шулай итеп Волга һәм Кама елгаларында 1940 нчы елның навигациясе тулай рәвештә башланып китте. Кичә, иртәнге сәгать 10 да Казан пристане Чистайдан килгән „Вера Засулич" пароходын каршылады һәм аны Рыбинскийга озатты.

Х. Максуд.

Үткән елгы җитешсезлекләр кабатлана

Казандагы төрле оешмалар пароходларга, баржаларга төяп җибәрү өчен причалларга төрле йөкләр китерә башладылар. Ләкин йөк кабул итүнең беренче көннәрендә үк зур гына җитешсезлекләр барлыгы күренде. Үткән елны булган ялгышлар быел да кабатланалар. Йөкләргә саксызлык белән карау аркасында үткән елны пристань 138 мең сум зарар күргән иде. Бу зур җитешсезлекне кабатламау өчен пристань җитәкчеләре бөтен чараларны күрделәр дип булмый әле. Йөк кабул итүче һәм аны җибәрүче иптәш Ненилин беренче рейс белән районнарга җибәрү өчен комбайн частьләре кабул итә. Ул комбайнның хедерләре өстенә башка йөкләр өйдерә, шулай итеп комбайн хедерләренә ватылу куркынычы тудыра.

Яисә тагын бер факт. Заготзерно оешмасы беренче рейс белән Чистай районына җибәрү өчен 75 тонна чәчүлек арпа китерде. Бу оешма тараларга һич тә әһәмият бирми. Тараларның сыйфаты бик начар. Бу җитешсезлек турында йөк кабул итүче иптәш Маркин пристань җитәкчеләренә үз вактында белдерсә дә, тиешле чара күрелми.

Мондый җитешсезлекләр пристаньдә еш очрыйлар. Йөкләрне дөрес саклау, аларны вактында кабул итү һәм җибәрү эшенә игтибар көчәйтелергә тиеш.

Ф. Исхаков.

В. И. Ленинның тууына 70 ел тулу көне алдыннан

Тарихи документлар

Татарстанның партия архивында Владимир Ильич Ленин тарафыннан 1900 нче елны оештырылган „Искра" газетасын таратуга караган документлар саклана. Газетада Казан социал-демократик партоешмасы һәм Казан предприятиеләрендәге эшчеләрнең тормышлары турындагы хәбәрләр һәм материаллар басылган.

Архив карамагында булган документлар арасында „Искра" программасын тарату турында РСДРП ның Казан Шәһәр Комитеты карары, Алафузов һәм Свешников заводлары эшчеләренең „Искра" газетасын укыганнан соң булган истәлекләре, шулай ук „Искра" газетасын укыган эшчеләрне кулга алу турында жандармерия управлениесенең документлары бар.

Биектау районында

Биектау районы колхозларында һәм предприятиеләрендә агитаторлар Владимир Ильич Ленинның тормышы һәм эше турында беседалар һәм чыгышлар ясыйлар. ВКП(б) райкомы тарафыннан расланган 60 докладчы 22 нче апрельдә колхозларда В. И. Ленинның тууына 70 ел тулу көненә багышланган докладлар ясый.

ВКП(б) райкомының партия кабинетында, мәктәпләрдә һәм китапханәләрдә В. И. Ленин әсәрләреннән күргәзмәләр һәм Ильичнең тормышы һәм эшчәнлеге турында фоторәсемнәрдән витриналар оештырылды. (ТатТАСС).

ВУЗ ЛАРДА ИЛЬИЧКӘ БАГЫШЛАНГАН ҖЫЕЛЫШЛАР

Казан Авыл Хуҗалыгы институтында Владимир Ильич Ленинның тууына 70 ел тулу көнен каршылау уңае белән Ленинның „Материализм һәм эмпириокритицизм", „Демократик революциядә социал-демократиянең ике тактикасы" дигән әсәрләре буенча фәнни работникларның беседалары булды. Бу беседалар зур активлык белән үтте. Шулай ук студентлар арасында беседалар уздырыла.

Студентлар һәм хезмәткәрләр арасында агитаторлар Владимир Ильич Ленин турында беседалар алып баралар. 22 нче апрельдә гомуми җыелышта „Владимир Ильич Ленин—ВКП(б) ның оештыручысы" темасына доклад куела. Институтта Владимир Ильич Ленинның тормышы һәм эшчәнлеге турында күргәзмә оештырылды. 31 нче мартта Владимир Ильич Ленин Музей йортына экскурсияләр дәвам итә.

Казан Дәүләт Педагогия институтында бүген Владимир Ильич Ленинның тууына 70 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш булачак. Гомуми җыелышта доклад ясала. Залда Ленинның революцион эшен күрсәтүче күргәзмә оештырылган.

ХАЛЫКАРА ХӘЛЛӘР ТУРЫНДА ДОКЛАД

Бүген, 21 нче апрель, кич 7 сәгатьтә Казан Дәүләт университетының актовый залында

Казан шәһәре интеллигенциясенең гомуми җыелышы чакырыла

Көн тәртибендә: Халыкара хәлләр турында ВКП(б) Үзәк Комитеты лекторы иптәш **Сазиков** доклады.

Җыелышка керү өчен билетлар ВКП(б) ның Шәһәр һәм Район Комитетлары аркылы таратыла.

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты.

Чит илләрдә

СКАНДИНАВИЯДӘ СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 19 апрель. (ТАСС). Рейтернең хәбәр итүенә караганда, Норвегиядә Намсос якынында Англия гаскәрләре белән Германия гаскәрләре арасында беренче бәрелеш булган. Германия гаскәрләренең атакасы кире кагылган. Германия гаскәрләре Тронгейм якынында урнашкан Вэрнес аэродромыннан самолетларда китерелгән отрядтан торган.

ЛОНДОН, 19 апрель. (ТАСС). Рейтернең хәбәр итүенә караганда, Норвегия хөкүмәтенең белдерүендә түбәндәгеләр күрсәтелә: „Норвегия яр буеның төрле пунктларында Англия гаскәрләрен төшерү дәвам итә. Коры җирдә һәм дингездә Норвегия гаскәрләре англичаннар белән контакт урнаштыралар. Хөкүмәт Норвегиянең төньяктагы армиясе командованиесеннән бу районнарда мобилизация үткәрүнең тәмам булганлыгы турында, шулай ук Норвегия гаскәрләре командованиесенең Германия көчләренә каршы тора алачаклыгы турында белдерү алды. Германия гаскәрләренең алга таба баруы акрын дәвам итә. Хәзер Германия гаскәрләренең урнашу линиясе Мьес күленнән, Рандсфиордтан һәм Сперилленнан көньякка таба үтә".

БЕРЛИН, 19 апрель. (ТАСС). Германия армиясе верховный командованиесенең хәбәр итүенә караганда, Нарвиктан төньяктарак Германия самолетлары дошманның десант төшерергә маташкан хәрби дингез көчләренә һәм транспортларына атака ясаганнар. Дошман карабларына зур зыян килгән. Бер су асты көймәсе батырылган. Берген һәм Ставангер районындагы Германия гаскәрләре бөтен юнәлешләр буйлап алга таба баруларын дәвам иттергәннәр. Осло районында Германия гаскәрләре төньяк-көнчыгыш һәм төньяк-көнбатыш юнәлешләрендә алга таба тиз баралар. Ослодан көньяк-көнчыгыштарак булган территория Швеция чигенә кадәр алынган. Бу районда норвегиялеләрнең 83 орудиесе, 80 пулеметы, 20 мең артиллерия снаряды һәм 1 миллион чамасы патроннары кулга төшерелгән. Германиянең хәрби дингез флоты Скагерракта һәм Каттегатта дошманның 3 су асты көймәсен юк иткән. Хардангер-фиордта норвегиялеләрнең бер миноносы юк ителгән.

Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Германия гаскәрләре Осло-фиордта Оскарсборг һәм Дребек крепостьларын алганнар.

ЛОНДОН, 19 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англия гаскәрләре Тронгеймнан 130 километр ераклыкта, Намсоста җиргә төшкәннәр. Норвегия гаскәрләре Намсостан 30 километр көньякта—Стейнкьерда тупланалар.

Көньяк Норвегиядән транспорт самолетларына төялеп Германия гаскәрләренә ярдәм китерелә.

Тронгейм бухтасында Германиянең зур йөк карабы күренде. Анардан танклар, авыр артиллерия һәм зенит орудиеләре бушатылды. Соңгы хәбәрләргә караганда, Германия гаскәрләре Тронгеймнан 30 километр ераклыкта Стьердальдәге аэродромны алганнар.

Хәбәр итүләренә караганда, Германиянең Тронгеймнан хәрәкәт итүче алдынгы отряды Сторлиеннан 5 километр ераклыктагы пунктка җиткән. Германия гаскәрләренең хәрәкәт итүләренә Норвегия гаскәрләренең чаңгычылар отрядлары кыенлык тудыралар.

Хәбәр итүләренә караганда, Англия самолетлары Тронгейм якынындагы Сейнтьердальдәге һәм Вэрнестагы аэродромнарны бомбага тотканнар. Германиянең 5 самолеты һәм бензин саклау урны юк ителгән. Норвегиянең Тронгеймнан 40 километр ераклыктагы Хегре крепостен норвегиялеләр кулларында тотуны дәвам иттерәләр.

Хәбәр итүләренә караганда, Англия гаскәрләре Нарвиктан көньякка таба хәрәкәт итәләр. Англия гаскәрләре составына Канада чаңгычылары отрядлары һәм артиллерия керә.

Ослодан төньяк-көнчыгышта, Эльверум районында каты сугышлар бара. Хәзер Германия гаскәрләре тауларда ныгыган норвегиялеләрнең зур көчләренә очрадылар.

Һиндстанда властьларга буйсынмау кампаниясенә хәзерлек

ЛОНДОН, 19 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Һиндстан милли конгрессының башкарма комитеты бюросы конгрессның җирле оешмаларын властьларга буйсынмау кампаниясен иглан итүгә хәзерләнергә чакырып карар чыгарган.

ЛОНДОН, 19 апрель. (ТАСС). Рейтернең хәбәр итүенә караганда, Һиндстан һәм Бирма эшләре министренең урынбасары О'нейл Хью түбәнге палатада болай дип белдергән: „Билгеле, Англия хөкүмәте Һиндстанга тулы бәйсезлек бирү турында Һиндстан милли конгрессының таләбен кабул итә алмый. Доминион статусын кабул итүдән Һиндстан милли конгрессының баш тартуына без тирәнтен кызгану белдерәбез" О'нейл Хью сүзендә дәвам итеп, Һиндстанга бәйсезлек бирү Һиндстанны Британия империясеннән тулысынча аеру дигән сүз булыр иде дип белдергән. Һиндстандагы хәлне өметсез дип карап булмый. Әгәр Һиндстанда властьларга буйсынмау кампаниясе башланса, хөкүмәт бу хәрәкәткә каршы тору өчен барлык чараларны күрәчәк.

Кытайдагы сугыш хәрәкәтләрен күзәтү

Үткән атнада Кытай фронтларында җирле әһәмиятле сугышлар булды. Көньяк Кытайдагы фронтта сугышлар Наньниннан көньяк-көнбатыштарак дәвам итте. Япон гаскәрләре 9 нчы апрельдә Наньнинга тәмам кысрыкландылар. Моннан берничә атна элек японнар тарафыннан Наньниннан көнбатышка, Һинд-Кытай чикләренә таба башланган һөҗүм әнә шулай тәмам булды.

Үзәк Кытайдагы фронтта Цзянси провинциясенең башкаласы—Наньчан районында һәм Ханькоудан төньяк-көнчыгыштарак Мачэн районында аеруча зур сугышлар булды. Мачэн районында булган каты сугышлардан соң японнар 9 нчы апрельдә шәһәрне ташлап чыктылар һәм кытай частьләре әзәрлекләгәнлектән чигенделәр. Бу районда японнарның 1.300 ләп кешеләре үтерелде һәм яраланды. Бу сугышларда кытай гаскәрләре дә зур югалтуларга дучар булдылар. Наньчан секторында, каты сугышларга карамастан, нинди булса да җидди үзгәрешләр булмады. Японнар нык-лы оборона ныгытмалары ясадылар һәм бу ныгытмалар японнарга үз позицияләрен кулларында тотарга ярдәм итәләр. Кытай гаскәрләре бу ныгытмаларны ала алмыйлар. Японнар монда күп тапкырлар ярдәм китереп тордылар. Бу гаскәрләр оборонаны дәвам иттерү өчен җитәрлек булса да, һөҗүм хәрәкәтләренә күчү өчен җитәрлек түгел. Хәзер төп сугышлар Наньчаннан төньяк-көнбатыштарак Аньи янында бара. Монда японнар көчле ныгытмалар ясаганнар.

Төньяк Кытайдагы фронтта төп сугышлар Шаньси провинциясендә бара. Ләкин бу сугышлар киң колач алмадылар әле. Ике якның да гаскәрләре аерым районнарга һәм пунктларга таралган. Гомуми фронт линиясе юк. Аерым бәрелешләр генә була. Шаньси провинциясендәге сугышларның характерлы ягы—сугышта инициативаның кытайлар ягында булуы. Японнар исә ныгытмаларында утырып оборона сугышлары алып баралар.

ЧУНЦИН, 19 апрель. (ТАСС).

ЛЕНИН ҺӘМ КОММУНИСТИК ИНТЕРНАЦИОНАЛ

I.

Ленин үзенең данлыклы революцион юлын рус эшчеләре арасында башлады. Ләкин ул чагында ук инде Ленин, барлык илләрдәге эшчеләр сыйнфының юлбашчысы, Маркс һәм Энгельс эшен турыдан-туры дәвам иттерүче сыйфатында бөтен дөнья күләмендәге тарих мәйданына чыкты,—үткән йөзнең ахрында бөтен дөнья революцион хәрәкәтенең үзәге безнең илебезгә күчә башлады.

Россия империализм каршылыкларының төп буыны гына түгел, бәлки аның иң йомшак урны булып та әверелде. Россиядәге черек самодержавие—крепостнойлык строе шул ук вакытта көнбатыш империалистларының терәге булды, царизм аларның ышанычлы союзнигы булды, империалистлар аны революциядән коткарырга вәгъдә биргәннәр иде. Ленин Россия пролетариатын һәм крестьяннәрен иске, патша Россиясенә, алпавытлар-буржуазия Россиясенә каршы кискен революцион штурмга хәзерләде һәм шуның белән инде ул вакытта ук бөтен дөнья империалистик буржуазиясенә каршы кискен көрәш хәзерләде.

Көнбатыш Европадагы социалистлар партияләрендә эш башында торучылар, марксизмнан чигенүчеләр Ленинның һәм большевикларның беренче адымнарына ничек карадылар соң? Башта—санга алмадылар, аннары—бик нык тынычсызландылар, ниһаять—явыз дошманлык һәм ачу белән карадылар. Бу кешеләр шул көннән башлап рус революциясенең төп мәсьәләләре бөтен дөнья революциясенең төп мәсьәләләре икәнлекне аңлый алмадылар һәм аңларга да теләмәделәр. Оппортунизм батвкаклыгына торган саен тирәнрәк чумучы II нче Интернационал „рыцарьлары" яңа тип партиянең—Ленин һәм Сталин төзегән (һәм төзеп җиткергән) партиянең капиталистик җәмгыятьнең килешмәүчән дошманы икәнлеген, димәк, социализмны бу җәмгыятькә „кушып үстерү" гә ачыктан-ачык яки читләтеп чакырган барлык „социалистлар"ның килешмәүче дошманы икәнлеген бик ачык күрделәр.

1914 нче ел, сугышка кадәр үк инде халыкара эшчеләр хәрәкәтендә төзелгән ике лагерьны да тикшерү елы булды. 1914 нче ел II нче Интернационалның хурлыклы рәвештә җимерелүе елы булды. 1914 нче елны Ленин яңа, Өченче Интернационал өчен көрәш байрагын күтәрде.

Бөтен дөнья күләмендәге беренче империалистик сугыш Ленинне көтелмәгән хәл алдында калдыра алмады. Моңа кадәр үк инде Ленин, марксизм тарихында беренче булып, революцион марксистик партиянең идеологик һәм оештыру нигезләрен үстергән иде. Бу нигезләр Ленин һәм Сталин тарафыннан төзелгән большевиклар партиясендә гәүдәләнделәр. Ленин марксистик партиянең тактик принципларын эшләде. Бу принциплар беренче рус революциясе барышында большевикларның тактикасында гәүдәләнделәр. Ленин марксистик партиянең теоретик нигезләрен яклады һәм саклап калды. Маркс, Энгельс таглиматын яңа баскычка күтәрде.

Сугыш тәҗрибәсе большевикларны чыныктырды. Сугыш тәҗрибәсе Ленин чакыруына кушылган башка илләрнең алдынгы пролетар революционерларын чыныктырды. Ленинның теоретик әсәрләрендә „даһиларча тупланган сугыш тәҗрибәсе, яңа туып килә торган Өченче Интернационалның идея арсеналына гаять әһәмиятле яңа хәзинә булды.

Ленин капитализмның соңгы стадиясенә фәнни анализ бирде. Бу анализ Ленингә сугыш мәсьәләләрендә, солых мәсьәләләрендә, революция мәсьәләләрендә большевикларның тактикасын дөрес билгеләү мөмкинлеген бирде. Бу анализ Ленингә аның даһи теориясенә ачкыч бирде, бу, марксистик теориянең алга таба гаять зур адымы булды. Ленин империализм шартларында социализмның барлык илләрдә бер вакытта җиңүе мөмкин түгеллекне, аерым алынган бер капиталистик илдә социализмның җиңүе мөмкинлеке фәнни яктан исбат итте.

1917—1918 нче елларда Ленин III нче Интернационал формаль рәвештә төзелмәгән булса да инде яши, көрәшә һәм җиңә дип күп тапкырлар әйтте һәм язды. Чыннан да, III нче Интернационалның төп лозунгысы—Советлар республикасы формасында пролетариат диктатурасы дигән Ленин лозунгысы—дөньяның иң зур илендә инде тормышка ашырылды. Советлар Россиясенең чикләре артында инде III нче Интернационал байрагы астына баскан сул пролетар группалар (ә Германиядә—Карл Либкнехт һәм Роза Люксембург җитәкчелегендә коммунистик партия) төзелде.

Бөтен дөнья картасында Ленин җитәкчелегендәге беренче Совет дәүләтенең килеп чыгуы, буржуазия лагерында паника тудырды. II нче Интернационал лидерьлары ярсыдылар; алар интервенциянең иң явыз тарафдарлары һәм оештыручылары арасында булдылар. Москва барлык илләрнең эшчеләре өчен төп үзәк булып әверелде! Димәк, Москва бетерелергә тиеш,—диделәр дошманнар. 1918—1920 нче елларда безнең Советлар Ватанының чикләре нинди генә чит ил байракларын һәм нинди генә генерал мундирларын күрмәде!

Ленин коммунистик Интернационалның идея һәм оештыру базасын төзеде. Шушы базада, большевизм базасында Ленин тарафыннан „яңа типтагы халыкара революцион пролетар оешма—коммунистик Интернационал, марксистик-ленинчел Интернационал төзелде". („ВКП(б) тарихының кыскача курсы", бит 263).

II.

Коминтернның беренче Конгрессында Ленин бөтен дөнья коммунистик партиясе байрагын күтәрде, буржуаз демократиянең чикләнгәнлеген һәм ялган икәнлеген фаш итте, чын демократиянең, хезмәт ияләре өчен демократиянең бары тик эшчеләр сыйнфы диктатурасын урнаштыру нәтиҗәсендә генә булуы мөмкин икәнлекне исбат итте.

II нче Конгресста Коминтернның төп программ, стратегик, тактик, оешу положениеләре киң җәелдерелде. Бу Конгрессның да йөрәге Ленин булды. Партиянең роле турындагы, эшчеләр сыйнфы белән крестьяннәр һәм империализм тарафыннан изелгән халыклар арасындагы союз турындагы, Коминтерн сафларын барлык төстәге оппортунистик сәләмәләрдән чистарту кирәклеге турындагы мәсьәлә—Ленин тарафыннан Конгресска куелган һәм хәл ителгән әһәмиятле мәсьәләләр әнә шулар.

III нче Конгресс алдыннан Ленин Коминтернның секцияләрен тагын да югары баскычка күтәрү бурычын куйды. Ленин Конгресста болай диде: „Безнең беренче адымыбыз чын коммунистик партия төзү иде... Икенче баскыч, партия булып оешып, революцияне хәзерләргә өйрәнүдән гыйбарәт булыр". (Әсәрләр, том XXVI, бит 446). Ленин бу Конгресста „Масса арасына!"—дигән лозунгны куйды.

1918—1920 нче еллар. Совет республикасы интервенциянең һәм блокаданың тимер боҗрасы эчендә булган хәлдә Англия—Франция—Япония—Польша ялчыларына каршы, буржуаз алпавыт-кулак ак гвардеецларына каршы сугышты. Гражданнар сугышында совет халкы Ленин һәм Сталин байрагы астында үзенең яңа тормыш төзү хокукын саклау өчен көрәште. Бу сугыш фронтларының чиксез күп сугышларында совет халкының куәтле армиясе—Ленин—Сталин Кызыл Армиясе туды һәм ныгыды.

Гражданнар сугышында СССР ның ялгыз булмавы бу сугышта безнең җиңүебезнең сәбәпләреннән берсе булды.

„Империалистлар Совет республикасын интервенция һәм блокада белән буарга маташкан вакытта, бу империалистик илләрнең эшчеләре Советлар ягында булдылар һәм Советларга ярдәм күрсәттеләр. Совет республикасына дошман булган илләрнең капиталистларына каршы көрәш алып барулары белән алар империалистларны интервенциядән баш тартырга мәҗбүр иттеләр". („ВКП(б) тарихының кыскача курсы", 279 бит). Советлар Россиясенең җиңүе шуның белән бергә бөтен халыкара пролетариатның җиңүе булды.

Коминтернның IV нче конгрессы Владимир Ильич чыгып сөйләгән соңгы конгресс булды. Конгресста аның доклады революциябезнең бишьеллыгына һәм бөтен дөнья революциясенең перспективаларына багышланды (конгресс 1922 нче елны булды). Ильичнең барлык соңгы речьләре һәм мәкаләләре Совет дәүләте интереслары белән халыкара пролетариат интересларының бердәмлеге турындагы фикер белән сугарылганнар.

Бездән киткәндә Ленин илебезнең иртәгәге көнен ачык күрде. Ул безгә илебездә социалистик җәмгыять төзү өчен, эшчеләрнең һәм крестьяннәрнең ныклы союзын саклау өчен, тарихта беренче социалистик дәүләтне ныгыту өчен армый-талмый көрәш алып барырга васыять итте.

Ленин капиталистик илләрнең иртәгәге көнен дә ачык күрде. Бу иртәгәге көн үзе белән бергә, һич шиксез, дөньяны, базарларны, колонияләрне, йогынты өлкәләрен яңадан бүлү өчен яңа империалистик сугыш, хезмәт ияләренең каннары яңадан түгелүне алып килде.

Ленин бөтен дөнья коммунистларына барыннан да элек барлык хезмәт ияләренең ватанын—Советлар Союзын саклап калырга һәм ныгытырга васыят итте. Ленин өйрәткәнчә, СССР да социалистик җәмгыятьнең үсүе һәм җиңүе бөтен дөньядагы хезмәт ияләренең үзләренең азатлыклары өчен уңышлы көрәшләренең иң яхшы гарантиясе булып тора.

Көнбатышта революцион стихиянең ялкыннары вакытлыча сүнеп торганда үлем Ленинне безнең сафтан тартып алды. Ләкин Ленин үзе башлаган эшнең киләчәктә җиңәчәген ачык күрде. Каты авырудан кәефе начарлангач, 1923 нче елның 2 нче мартында әйтеп яздырган соңгы мәкаләсендә Владимир Ильич капиталистик илләрдәге хезмәт ияләренең киләчәктә җиңүләре тәэмин ителгәнлекне тәмам ышану белән раслады.

Ильич үлгәннән соң үткән 16 ел эчендә СССР ның һәм Коминтернның бөтен тарихы бөек Сталин җитәкчелегендә барлык илләрдәге коммунистларның Ленин васыятьләрен тормышка ашыру өстендә тайпылышсыз эшләүләрен күрсәтә.

Үлем Ленинне совет халкы сафыннан һәм Коммунистик Интернационал сафыннан тартып алганда СССР да социализмның беренче нигез ташлары гына һәм коммунизмның бөтен дөнья партиясенең беренче нигез ташлары гына салынган иде әле. Юлның төп юнәлеше Ленин тарафыннан даһи рәвештә күрсәтелде. Ләкин иң зур кыенлыклар һәм хәл иткеч сугышлар алда иде әле.

1924 нче елның азагында иптәш Сталин „Көнбатышта Европадагы киләчәк революциянең таянычы булган чын большевистик партияләрнең тәмам формалашуы процессы"ның әле башланган гына булуы турында язды. Хәзер инде һәрбер илдә эшчеләр сыйнфының алдынгы кешеләре, коммунистлар, Ленинның һәм Сталинның даһи әсәрләренең коммунизм өчен миллионнарча ныклы көрәшчеләрне рухландыруларын һәм тәрбияләүләрен раслыйлар.

Барлык илләрдәге хезмәт ияләре өчен илебезнең әһәмияте чиксез үсте. СССР ның экономик, техник һәм хәрби куәте чиксез үсте.

Совет халкы үзенең бөтен дөньядагы барлык хезмәт кешеләренең бердән-бер һәм ышанычлы союзнигы икәнлеген беләКоммунистик Интернационалга нигез корган Ленинның гробы өстендә иптәш Сталин бар кешеләрнең дә исләрендә калган сүзләрне әйтте: „Ант итәбез сиңа, иптәш Ленин, без бөтен дөнья хезмәт ияләренең союзын — Коммунистик Интернационалны ныгыту һәм киңәйтү өчен үзебезнең тормышыбызны аямабыз!".

Бу ант үтәлә.

М. Зоркий.

Редактор урынбасары **И. ҮЗБЕКОВ.**
Зам. редактора **И. УЗБЕКОВ.**

ТЕАТР ҺӘМ КИНОЛАРДА:

Татар Дәүләт Академия театрында—23 нче апрельдә Н. Исәнбәт әсәре премьера **Хуҗа Насретдин.**

Татар Дәүләт Опера театры—ТДАТ бинасында бүген—Файдасызга саклану.

Зур театр—премьера Метель.

Дәүләт циркы—бүген 3 бүлектә зур цирк уены һәм французча көрәш ярышы.

„Электро"—Аринка. „Унион"—Моряклар. „Кызыл Йолдыз"—Шатлык эзләгәндә. „Чаткы"—Ташландык. „Пионер"—Инженер Кочинның ялгышуы. „Колхозник"—Яңа заманнар. „Рот-Фронт"—Шәхси эш. Культура сарае—Истребительләр.

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 1529. ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 1525.